ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ТУКТАРОВО-УРДАЛИНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ТУКТАР-УРДАЛАСЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 нче елның 2 мае №10

Лениногорск муниципаль районы «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 нче елның 3 нче августындагы 16 нчы номерлы карары белән расланган Адреслар бирүны, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Хекүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 5 февралендәге 124 номерлы карарына ярашлы итеп, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Лениногорск муниципаль районы «Туктар-Урдаласы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 нче елның 3 нче августындагы 16 номерлы карары белән расланган Адреслар бирүны, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 1.2 пунктның 10 нчы абзацында «Әлеге пунктта күрсәтелгән зат исеменнән» дигән сүзләрне «Гариза белән»дигән сүзләр белән алыштырырга;

2) 1.5 пунктның 9 һәм 10 нчы абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«планлаштыру структурасы элементы - зона (массив), район (шул исәптән торак район, микрорайон, квартал, сәнәгать районы), яр буе, гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык алып бару территориясе;

урам - юл челтәре элементы -урам, проспект, тыкрык, юл, мәйдан, бульвар, тупик, съезд, шоссе, аллея һәм башкалар;»;

3) 2.3.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3.2. Адреслашу объектына яңа адрес бирелгән очракта адреслашу объектының адресын гамәлдән чыгару турындагы карар әлеге объектка яңа адрес бирү турындагы карар белән берләштерелә.»;

4) 2.4 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген исәпкә алып, муниципаль

хезмәт күрсәтүне туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору вакыты, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) вакыты

2.4.1. Адреслашу объектына адрес бирү яки аның адресын гамәлдән чыгару турында карар кабул итү, адреслашу объектына адреслашудан баш тарту яки аның адресын гамәлдән чыгару турында карар кабул итү, шулай ук адреслашу объектының адресы турында тиешле мәгълүматны дәүләт адрес реестрында урнаштыру вәкаләтле орган тарафыннан башкарыла:

а) гариза кәгаз формада бирелгән очракта - гариза кергән көннән алып 10 эш көненнән дә артык булмаган вакытта;

б) электрон документ формасында гариза бирелгән очракта гариза килгән көннән алып 5 эш көненнән дә артык булмаган срокта.

2.4.2. Вәкаләтле орган тарафыннан объектка адресны бирү яки аның адресын гамәлдән чыгару турында карар кабул ителгән очракта, регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән физик яки юридик затларның гаризалары нигезендә, адреслашу объектының адресы турында мәгълүматны дәүләт адреслашу реестрында урнаштыру буенча федераль мәгълүмат адреслашу системасы операторы вәкаләтле орган соравы буенча адреслашу объектының адресы турында мәгълүматны дәүләт адреслашу реестрында урнаштырганнан соң бер календарь көннән дә соңга калмыйча вәкаләтле органга адреслашу объектының адресы турында дәүләт адреслашу реестрыннан өземтә бирә яки адрес системасы порталын яки ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын кулланып, дәүләт адрес реестрында мәгълүмат булмау турында белдерү.

2.4.3. Гариза күпфункцияле үзәк аша тапшырылган очракта, Регламентның 2.4.1 пунктында күрсәтелгән вакытта күпфункцияле үзәк тарафыннан Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар тапшырылганнан соң, вәкаләтле органга тапшырыла.

2.4.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогын туктатып тору каралмаган.».

2. Әлеге карарны Лениногорск районы, Туктар-Урдаласы авылы, Совет урамы, 98 йорт, Совет урамы, 103 йорт, Карагай авылы, Тельман урамы, 31 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә (https://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
«Туктар-Урдаласы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы

Г.Ә.Әхмәтова